| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от 04.12.2014** г. Казань **№ 389**

**Электр һәм газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен, бу нормативларны билгеләү ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар башлангычы белән эшләнгән очракта, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар исемлеген һәм эчтәлеген билгеләү турында**

“Коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын билгеләү һәм ачыклау Кагыйдәләрен раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 23 май № 306 карарына, Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 15.06.2010 № 468 карары белән раслаган Нигезләмәгә туры китереп,

б о е р а м:

1. Электр белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен, бу нормативларны билгеләү ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар башлангычы белән эшләнгән очракта, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар исемлеген һәм эчтәлеген, шушы боерыкның 1 кушымтасы белән килештереп билгеләргә.

2. Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен, бу нормативларны билгеләү ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар башлангычы белән эшләнгән очракта, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан Татарстан Республикасының тарифлар буенча

Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар исемлеген һәм эчтәлеген, шушы боерыкның 2 кушымтасы белән килештереп билгеләргә.

3. Ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан кергән документларга анализ ясаганда, аларны төгәлләштерү кирәк булган очракта, Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты (алга таба – вәкаләтле орган) запросны дәлилләп, өстәмә мәгълүматларны соратып ала. Шундый мәгълүматларны бирү вакытын вәкаләтле орган билгели, ләкин ул ресурслар белән белән итү оешмаларына запрос ясалган көннән башлап, 7 көннән дә кимрәк була алмый.

4. Шушы боерык рәсми басылгач, ун көннән соң, үз көченә керә..

Рәис: М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгына 1 кушымта
_____________ № _________

Электр белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен, бу нормативларны билгеләү ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар башлангычы белән эшләнгән очракта, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар исемлеге һәм эчтәлеге

1) Электр белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү турында вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүнең сәбәпләре һәм дәлилләре мәҗбүри күрсәтелгән гариза (оешма җитәкчесе имзалаган, мөһер сугылган);

2) гаризага бөркетелгән һәр документның атамасы, битләр саны мәҗбүри күрсәтелгән исемлек;

3) оешма уставы күчермәсе;

4) дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;

5) салым органында исәпкә бастыру турында таныклык күчермәсе;

6) милек хокукын раслаучы хокук билгеләүче документларның күчермәләре ( гражданлык – хокукый килешүләр, концессия килешүләре), көйләүле эшчәнлекне үтәүдә файдаланыла торган күчемсез милек ( биналар,

төзелешләр, корылмалар, җир участоклары) обьектларына хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән идарә итүгә карата башка законлы нигез;

7) оешма мәнфәгатьләрен тәкъдим итүче шәхеснең вәкаләтен раслаучы документ;

8) Россия Федерациясе Хөкүмәте 2006 елның 23 май № 306 карары белән раслаган коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын билгеләү һәм ачыклау Кагыйдәләре нигезендә үтәлгән электр белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары исәпләмәсе;

9) коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын исәпләүгә аңлатма язуы;

10) охшаш ысулларны кулланган очракта:

10.1) күп фатирлы йортлар яки шуңа охшаш конструктив һәм техник үлчәнешле торак йортлар, күп фатирлы һәм торак йортларның төзеклеге дәрәҗәсен исәпкә алып, һәр төр күп фатирлы һәм шәхси йортларның адреслары, фатирлар, катлар, бүлмәләр саны күрсәтелгән исемлек;

10.2) Аерым күп фатирлы йортта яки торак йортта коллектив (гомуми йорт) исәпләү җайланмалары яки торак йортлардагы индивидуаль исәпләү җайланмалары күрсәткечләре белән билгеләнгән июнь һәм ноябрь айларына, 1 һәм 30 июньгә, 1 һәм 30 ноябрьгә исәпләү җайланмалары күрсәткечләре теркәлгән актлар кушымтасын кертеп, электр энергиясенең айлык чыгымы;

10.3) 1 һәм 30 июньгә, 1 һәм 30 ноябрьгә барлык индивидуаль исәпләү җайланмалары күрсәткечләре теркәлгән кушымта белән, июнь һәм ноябрь

айларына барлык индивидуаль исәпләү җайланмаларының электр энергиясенә айлык чыгымы. Актлар исәпләү җайланмалары күрсәткеченең датасын һәм вакытын күрсәтеп, йортта яшәүче, йортның әйдәүчесе, ресурслар белән тәэмин итү оешмасы вәкиле имзасы белән расланган булырга тиеш ;

10.4) һәр фатирда, күп фатирлы йортта, шәхси йортта яшәүчеләр саны;

10.5) июнь һәм ноябрь айларына  торак булмаган биналарда торак булмаган бинаның милек иясе имзасы белән расланган айлык электр энергиясе чыгымы;

10.6) күп фатирлы йортта торак һәм торак булмаган биналар, шулай ук йортның паспорты буенча гомуми милеккә керүче биналар ( шундый биналар исемлеген күрсәтеп) мәйданы;

11) исәпләү ысулын кулланган очракта:

11.1) исәпкә алынучы 1 кеше яшәүче гадәти бер бүлмәле фатир мәйданы;

11.2) 1 бүлмәле фатирда электр энергиясенең еллык чыгымы;

11.3) күп фатирлы йортларның барлык төр проектлары буенча, күп фатирлы йортның гомуми милке булган җиһазларның исемлеге, саны һәм төрләре;

11.4) күп фатирлы йортның гомуми милке составына керүче һәр төр җиһазның, санын һәм эшләү вакытын, күәтен, һ.б. күрсәтеп, электр энергиясен куллануы;

11.5) күп фатирлы йортның гомуми милек составына керүче биналары (шундый биналарның исемлеген күрсәтеп) мәйданы;

11.6) тиешле төрдәге авыл хуҗалыгы хайваннарын тоту максатларында яктыртуга электр энергиясе чыгымнары (1 баш хайванга елына кВт.с);

11.7) тиешле төрдәге авыл хуҗалыгы хайваннарына азык әзерләү һәм су җылытуга электр энергиясе чыгымнары (1 баш хайванга елына кВт.с);

11.8) башка ишегалды корылмаларына электр энергиясе чыгымнары.

Шушы кушымтаның 10, 11 пунктларында каралган документлар, кәгазьдә (саннар куелган битләр белән) һәм электрон рәвештә тапшырыла.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының боерыгына 2 кушымта
_____________ № _________

Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен, бу нормативларны билгеләү ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар башлангычы белән эшләнгән очракта, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар исемлеге һәм эчтәлеге

1) Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү турында вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүнең сәбәпләре һәм дәлилләре мәҗбүри күрсәтелгән гариза (оешма җитәкчесе имзалаган, мөһер сугылган);

2) гаризага беркетелгән һәр документның атамасы, битләр саны мәҗбүри күрсәтелгән исемлек;

3) оешма уставы күчермәсе;

4) дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;

5) салым органында исәпкә бастыру турында таныклык күчермәсе;

6) милек хокукын раслаучы хокук билгеләүче документларның күчермәләре ( гражданлык – хокукый килешүләр, концессия килешүләре), көйләүле эшчәнлекне үтәүдә файдаланыла торган күчемсез милек ( биналар, төзелешләр, корылмалар, җир участоклары) обьектларына хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән идарә итүгә карата башка законлы нигез;

7) оешма мәнфәгатьләрен тәкьдим итүче шәхеснең вәкаләтен раслаучы документ;

8) Россия Федерациясе Хөкүмәте 2006 елның 23 май № 306 карары белән раслаган коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын билгеләү һәм ачыклау Кагыйдәләре нигезендә үтәлгән электр белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары исәпләмәсе;

9) коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын исәпләүгә аңлатма язуы;

10) исәпләү җайланмалары белән җиһазландырылган һәм җиһазландырылмаган күп фатирлы һәм торак йортларның адреслы исемлеге, күрсәтелгән адреслар мондый эчтәлектәге мәҗбүри мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

шушы йортлардагы фатирлар санын;

торак биналары мәйданын;

торак биналарда газ плитәләре булуын һәм үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин ителүен;

торак биналарда газ плитәләре булуын һәм үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин ителмәвен, газ су җылыткычы булуын;

торак биналарда газ плитәләре булуын, үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин ителмәвен, газ су җылыткычы булмавын;

яшәүчеләр санын;

11) күп фатирлы яки торак йортларның төзеклеге дәрәҗәсе, коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары билгеләнгән вакыт эчендә, һәр исәпләү җайланмасының (индивидуаль, коллектив, гомуми йорт) айлар буенча газ куллану күләмнәре ( исәпләү җайланмалары һәм гамәлдәге нормативлар буенча) күрсәтелгән мәгълүматлар

12) охшаш ысулларны кулланган очракта:

12.1) күп фатирлы һәм торак йортларның төзеклеге дәрәҗәсен исәпкә алып, күп фатирлы йортлар яки шуңа охшаш конструктив һәм техник үлчәнешле торак йортларда урнаштырылган газ куллануны исәпләү җайланмаларыннан алынган ( 1 ел эчендә һәр ай саен) күләмнәр турында мәгълүматлар;

12.2) исәпләү җайланмалары күрсәткечләре күләмнәрен алуны үткәрү планы;

12.3) исәпләү җайланмаларыннан алынган күләмнәр мәҗбүри күрсәтелгән актлар, күп фатирлы яки торак йортның адресы, торакта яшәүчеләр саны, фатирлар саны, температура һәм басым буенча махсус корректорлары булган исәпләү җайланмалары күрсәткечләрен алу датасы һәм вакыты, сыек углеводород газны айлык уртача куллану (кирәк булганда, аны куллануның һәр юнәлеше буенча);

12.4) исәпләү җайланмасы алдында урнашкан ноктада үлчәнә торган сыек углеводород газының температурасы һәм басымы, факттагы барометр басымы (сыек углеводород газы чыгымнарын билгеләгәндә) турында мәгълүматлар;

12.5) Күзәтелә торган вакыт эчендә газның факттагы чыгымнарын күзәтү нәтиҗәләре буенча, шул исәптән торакта яшәүче бер кешегә бер айга фактта газ куллану күләме күрсәтелгән исемлек. Газ куллануның сезонга бәйле рәвештә тигез бүленмәвен исәпкә алып, һәр обьект буенча газ чыгымнарын күзәтү ай саен бер ел дәвамында үткәрелә;

12.6) күләмнәрне алуга кадәр һәм аларны алу вакытында күп фатирлы йортны һәм торак йортны төзекләндерү һәм йорт эчендә инженер челтәрләрен көйләү буенча чираттан тыш эшләр үткәрелмәвен раслаучы документ

Шушы кушымтаның 10, 12 пунктларында каралган документлар, кәгазьдә (саннар куелган битләр белән) һәм электрон рәвештә тапшырыла